**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлегенең Мөэмин-Каратай торак пунктында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2023 елның 18 ноябре №2

**2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Мөэмин-Каратай авыл җирлегенең Мөэмин-Каратай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану турында**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Мөэмин-Каратай авыл җирлеге Мөэмин-Каратай торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда үзара салымны Лениногорск муниципаль районының Мөэмин-Каратай авыл җирлеге Мөэмин-Каратай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, , балачактан инвалидлар, 1 төркем инвалидларыннан; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан; Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарының тол хатыннарыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

Механизаторлар урамында халыкның күпләп ял итү урыны булган паркны тотып алу.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мөэмин-Каратай авылы,Механизаторлар ур., 31Б адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы Ә.А.Ханнанова